**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**2028 елга кадәр Татарстан Республикасының Инвестиция декларациясенә үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «2028 елга кадәр Татарстан Республикасының Инвестиция декларациясе турында» 2012 елның 18 июнендәге ПУ-477 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2021 елның 30 ноябрендәге ПУ-920 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 5 июлендәге 474 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган 2028 елга кадәр Татарстан Республикасының Инвестиция декларациясенә (алга таба – Инвестиция декларациясе) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төп капиталга илкүләм үсеш максатына ирешүгә акча салу рәвешендә инвестицияләр күләмен арттыруны тәэмин итү – 2030 елга 2020 ел дәрәҗәсе белән чагыштырганда кимендә 60 процентка (Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы мәгълүматлары буенча, 2020 елда – 615 593 млн сум;»;

б) 2.2 пунктның «в» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Агентлык тарафыннан инвестиция проектларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын тормышка ашыруда «бер тәрәзә» принцибы буенча ярдәм итү буенча инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлеге регламентын раслау турында» 2019 елның 20 февралендәге 118 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын тормышка ашыруда «бер тәрәзә» принцибы буенча ярдәм итү буенча инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлеге регламенты нигезендә башкарыла.

Инвестиция проектын гамәлгә ашыру максатларында инвесторга Регламентның 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча инвестиция проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча булышлык күрсәтү турында гаризаны, шулай ук Регламентның 1 нче кушымтасында бирелгән форма буенча инвестиция проекты йомгагын Агентлыкка җибәрергә тәкъдим ителә. Документлар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша электрон почта адресына (tida@tatar.ru) яисә, Регламентның 3 нче кушымтасында бирелгән «Татарстан инвестицияләрен контрольдә тоту» мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәгә таянып, «Татарстан

инвестицияләрен контрольдә тоту» мәгълүмат системасыннан файдаланып тапшырылырга мөмкин. Инвестиция эшчәнлеге субъектларына консультация бирү, мәгълүмати һәм хокукый ярдәм күрсәтү (843) 570-40-01 номерлы телефон аша гамәлгә ашырыла.

Инвестиция проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итүнең җентекле схемасы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Инвестиция порталында (invest.tatarstan.ru/ru/) бирелә;»;

в) 3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле барлык шартлар да бар.

Татарстан Республикасында, Россия Федерациясе законнары нигезендә бирелә торган инвестиция эшчәнлегенә дәүләт ярдәменең федераль чараларын исәпкә алып, инвестиция эшчәнлегенә түбәндәге дәүләт ярдәме чаралары карала:

1) «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законы («Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) нигезендә төзелгән инвестиция проектын гамәлгә ашыру турындагы шартнамә нигезендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен оешмалар мөлкәтенә салым буенча преференцияләр:

проектны гамәлгә ашыру өчен оешма тарафыннан яңа булдырылган яки сатып алынган мөлкәткә салым ставкасын инвестицияләр башланган вакыттан алып җиде елга кадәр, ә машиналар төзү тармагында инвестицияләр башланган вакыттан алып 13 елга кадәр киметү. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2011 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең 2-5 пунктындагы икенче абзацында билгеләнгән шартлар үтәлгәндә, оешмалар мөлкәтенә салым исәпләнгән салым суммасының 4,55 процент күләмендә түләнә;

Татарстан Республикасы территориясендә проект куәте елына кимендә 500 мең тонна этилен җитештерү куәтләрендә пиролиз ысулы белән этилен җитештерүне гамәлгә ашыра торган, капитал салулар күләме кимендә 10 млрд сумлык инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы оешмалар өчен җиде елга кадәр срок белән мөлкәткә салым түләүдән азат итү;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергиясен һәм куәтен күпләп сату базары кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең электр энергиясен һәм куәтен күпләп сату базары эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 27 декабрендәге 1172 номерлы карары нигезендә үткәрелгән конкурс нәтиҗәләре буенча сайлап алынган, җитештерү һәм куллану калдыкларыннан файдалану нигезендә эшли торган генерацияләү объектларын төзү (реконструкцияләү, модернизацияләү) буенча инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы оешмалар өчен объектны файдалануга

тапшырган вакыттан 15 елга кадәр срок белән мөлкәткә салым түләүдән азат итү;

2) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергиясен һәм куәтен күпләп сату базары кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең электр энергиясен һәм куәтен күпләп сату базары эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 27 декабрендәге 1172 номерлы карары нигезендә үткәрелгән конкурс нәтиҗәләре буенча сайлап алынган, җитештерү һәм куллану калдыкларыннан файдалану нигезендә эшли торган генерацияләү объектларын төзү (реконструкцияләү, модернизацияләү) буенча төбәк инвестиция проектларында катнашучылар өчен оешмалар табышына салымның киметелгән ставкалары («Татарстан Республикасы территориясендә төбәк инвестиция проектларын гамәлгә ашырганда салым салуның аерым мәсьәләләрен җайга салу турында» 2022 елның 21 мартындагы 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы):

0 процент – Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле салымның киметелгән ставкасын куллану чоры дәвамында федераль бюджетка күчерелергә тиешле салым буенча;

10 процент – төбәк инвестиция проектын гамәлгә ашырудан беренче табыш алынган салым чорыннан башлап һәм 20 процент күләмендәге ставкадан чыгып исәпләнгән салым суммасы белән әлеге хисап (салым) чорлары өчен арта бара торган йомгак белән билгеләнгән, киметелгән ставкаларны кулланып исәпләп чыгарылган салым суммасы арасындагы аерма төбәк инвестиция проектын гамәлгә ашыру максатларында башкарылган капитал салулар күләменә тигез күләмдә булган хисап (салым) чоры белән тәмамлана торган, Татарстан Республикасы бюджетына исәпләнергә тиешле салым буенча.

Төбәк инвестиция проектларында катнашучылар өчен оешмалар табышына салымның киметелгән ставкалары 2029 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә була. Шул ук вакытта Россия Федерациясе Салым кодексының 25.8 статьясындагы 1 пунктының 4 пунктчасындагы икенче абзацында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган төбәк инвестиция проектларында катнашучылар 2027 елның 1 гыйнварыннан оешмалар табышына салым буенча киметелгән ставкаларны куллану хокукын югалта;

3) «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы резидентлары өчен преференцияләр (Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында» 2005 елның 22 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон, «Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы резидентлары-оешмалары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын

билгеләү турында» 2006 елның 10 февралендәге 5-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының «Җиргә салым турында» 2005 елның 29 ноябрендәге 13 номерлы карары):

ирекле таможня зонасы режимы;

10 ел дәвамында оешмалар мөлкәтенә салым, транспорт салымы, җир салымы түләүдән азат итү;

Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле оешмалар табышына салымның киметелгән ставкаларын куллану:

0 процент – салым салынырга тиешле табыш беренче тапкыр алынган салым чорыннан башлап, беренче биш салым чоры дәвамында;

5 процент – киләсе биш салым чоры дәвамында;

13,5 процент – алга таба;

федераль бюджетка күчерелергә тиешле оешмалар табышына салымның киметелгән ставкасын 2% күләмендә куллану;

4) «Иннополис» махсус икътисадый зонасы резидентлары өчен техник-гамәлгә кертү тибындагы преференцияләр (Россия Федерациясе Салым кодексы, «Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона һәм Татарстан Республикасының Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнары территорияләрендә төзелгән «Иннополис» техник-гамәлгә кертү тибындагы махсус икътисадый зонасы резидентлары-оешмалары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2006 елның 10 февралендәге 5-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы):

10 салым чоры дәвамында оешмалар мөлкәтенә салым, транспорт салымы түләүдән һәм биш салым чоры дәвамында – җир салымы түләүдән азат итү;

Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле оешмалар табышына салымның киметелгән ставкаларын куллану:

0 процент – салым салынырга тиешле табыш беренче тапкыр алынган салым чорыннан башлап, беренче биш салым чоры дәвамында;

5 процент – киләсе биш салым чоры дәвамында;

13,5 процент – алга таба;

федераль бюджетка күчерелергә тиешле оешмалар табышына салымның киметелгән ставкасын 2 процент күләмендә куллану;

5) үсеше алга киткән тиешле территория булдыру турында килешүләр гамәлдә булган чорда «Чаллы», «Түбән Кама», «Зеленодольск», «Чистай» һәм «Менделеевск» кебек үсеше алган киткән территорияләр резидентлары өчен преференцияләр (Россия Федерациясе Салым кодексы, Татарстан Республикасы Җир кодексы, «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен оешмалар табышына

салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2016 елның 13 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының «Җиргә салым турында» 2016 елның 9 ноябрендәге 11/6 номерлы карары, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының «Җиргә салым турында» 2020 елның 15 октябрендәге 12 номерлы карары, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының «Зеленодольск шәһәре территориясендә 2020 елның 1 гыйнварыннан җиргә салым ставкалары, түләү тәртибе турында» 2019 елның 13 ноябрендәге 264 номерлы карары, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымын гамәлгә кертү, ставкаларын, түләү тәртибен билгеләү турында» 2016 елның 10 ноябрендәге 9/1 номерлы карары, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең «Җиргә салым турында» 2020 елның 3 ноябрендәге 6 номерлы карары):

дәүләт яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен, сатулар үткәрмичә, арендага бирү буенча ташламалы шартлар;

җир салымын һәм оешмалар мөлкәтенә салымны түләүдән азат итү;

оешмалар табышына салымның киметелгән ставкаларын куллану:

а) федераль бюджетка күчерелергә тиешле салым өлешендә:

0 процент – үсеше алдан билгеләнә торган территориядә эшчәнлек башкару турында килешүне үтәгәндә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән беренче табыш алынган вакыттан алып биш салым чоры дәвамында;

3 процент – алга таба;

б) Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле салым өлешендә:

5 процент – үсеше алдан билгеләнә торган территориядә эшчәнлек башкару турында килешүне үтәгәндә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән беренче табыш алынган вакыттан алып биш салым чоры дәвамында;

10 процент – алдагы биш салым чоры дәвамында;

б) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган Татарстан Республикасы индустриаль (сәнәгать) парклары резидентлары өчен преференцияләр («Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 8 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен дифференциацияләнгән салым ставкаларын билгеләү турында» 2009 елның 17 июнендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы:

транспорт салымын түләүдән һәм оешмалар мөлкәтенә салымнан азат итү;

салым салуның гадиләштерелгән системасы буенча киметелгән салым ставкаларын билгеләү:

1 процент – салым салу объекты буларак керемнәрен билгеләгән салым

түләүчеләр өчен;

5 процент – салым салу объекты буларак чыгымнар күләменә киметелгән керемнәрен билгеләгән салым түләүчеләр өчен.

Преференцияләр индустриаль (сәнәгать) парк территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашыру турында килешү төзелгән датага индустриаль (сәнәгать) парк мәйданын иң күбе 70 процент биләү шарты белән бирелә һәм индустриаль (сәнәгать) парк территориясендә 10 ел дәвамында кулланыла.

Моннан тыш, кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасы территориясендә түбәндәге оешмалар эшли:

«Татарстан Республикасының эшкуарларга ярдәм фонды» коммерциячел булмаган микрокредит оешмасы кече һәм урта эшкуарлык оешмаларына займнар, эшкуарлыкка республикакүләм һәм федераль ярдәм чаралары турында консультацияләр һәм мәгълүмат бирү, укытуга һәм проектларга җитәкчелек итү рәвешендә ярдәм күрсәтә, шулай ук башка хезмәтләр күрсәтә;

«Татарстан Республикасының гарантия фонды» коммерциячел булмаган оешмасы кече һәм урта эшкуарлык субъектлары, үзмәшгуль гражданнар һәм оешмалар йөкләмәләре буенча гарантияләр бирә һәм поручительлек күрсәтә.

7) кулланылган электр энергиясе өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булган индустриаль (сәнәгать) паркларның резидентларына һәм идарәче компанияләренә кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 28 июнендәге 505 нче карары);

8) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бер үк вакытта мәҗбүри яклар булып торган махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен преференцияләр (Россия Федерациясе Салым кодексы, «Махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» 2017 елның 2 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы):

оешмалар табышына Татарстан Республикасы бюджетына кертелергә тиешле салым буенча киметелгән ставкалар куллану:

а) федераль бюджетка күчерелергә тиешле салым өлешендә – 0 процент Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле салымның киметелгән ставкасын куллану чоры дәвамында;

б) Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле салым өлешендә:

0 процент (2025 елга кадәр (2025 елны кертеп) – йөк автотранспорт чаралары җитештерүчеләр булып торган махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен;

13,5 процент – махсус инвестиция контрактларында катнашучы башка оешмалар өчен;

йөк автотранспорт чаралары җитештерүчеләр булып торган махсус инвестиция контрактларында катнашучы оешмалар өчен оешмалар мөлкәтенә салым буенча – салым махсус инвестиция контракты гамәлдә булган срок эчендә, әмма иң күбе 10 ел дәвамында исәпләнгән салым суммасының 4,55 процент күләмендә түләнә;

9) «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның $111^4$ статьясы нигезендә кара-каршы инвестиция йөкләмәләре белән контракт төзү. Әлеге контрактны төзү мәсьәләләре буенча республика башкарма хакимият органнарының үзара хезмәттәшлеге тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнарының кара-каршы инвестиция йөкләмәләре белән контракт төзү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлеге тәртибен раслау турында» 2023 елның 22 июнендәге 737 нче карары белән расланды;

10) капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турындагы килешүләргә бәйле берничә шартнамәне тану, шулай ук инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында тиешле һәм тәэмин ителә торган инфраструктура объектларын төзү чыгымнарын компенсацияләү мөмкинлеген тәэмин итү максатларында эшкуарлык һәм (яисә) башка эшчәнлек алып баруның салым һәм башка җәйга салу шартларын тотрыкландыру максатларында капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешү төзү («Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон);

11) концессия килешүләре, дәүләти-хосусый партнерлык һәм муниципаль-хосусый партнерлык турында килешүләр төзү («Концессия килешүләре турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон).

«Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеген үстерү максаты белән төзелде һәм түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

проектларны гамәлгә ашыруга максатчан заемнар бирү;

портфельле сәнәгать проектларын үстерү;

инвестиция эшчәнлеген үстерүгә, шул исәптән фәнни эшләнмәләргә грантлар бирү («Идея-1000» инновация проектларына ярдәм күрсәтү программасы һәм «Ел инновациясе» республика конкурсы кысаларында);

акселерация программалары һәм ярдәм күрсәтүнең башка рәвешләре аша инновация проектларын үстерү, компанияләрне Россия һәм халыкара базарларга чыгаруда булышлык күрсәтү.

Муниципаль ярдәм чаралары (җир салымын түләүдән азат итүне, җир кишәрлекләрен арендага алучыларны аренда түләүләреннән азат итү яисә ташламалы шартларда аренда түләүләрен гамәлгә ашыруны, эшчәнлекнең сайланган төрләре буенча түләүсез, сатуга куймыйча мөлкәт бирүне, хезмәтләрнең кайбер төрләрен күрсәткәндә чыгымнарның бер өлешен каплауны, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә кредит буенча ташламалы ставканың бер өлешенә субсидия бирүне кертеп) Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә бирелә.

Ярдәм чаралары турында җыелма мәгълүматтан һәркем файдалану мөмкинлеге «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Инвестиция порталының «Ярдәм чаралары» бүлегендә (invest.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең республика органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары сайтларында, махсус икътисадый зоналар, үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр, индустриаль (сәнәгать) парклар һәм инвестиция инфраструктурасының башка объектлары сайтларында басмалар бирү, шулай ук инвестиция юнәлешендәге ачык чаралар ярдәмендә тәэмин ителә.»;

г) 3.14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.14. Инвестиция эшчәнлегендә катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан өч елга Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеген үстерү өстенлекләре билгеләнә торган Татарстан Республикасы Инвестиция меморандумы раслана.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023–2025 елларга Татарстан Республикасы Инвестиция меморандумын раслау турында» 2022 елның 7 декабрендәге 1296 нчы карарында 2023–2025 елларга Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеген үстерүнең төп өстенлекле юнәлешләре билгеләнде, шул исәптән:

инвестицияләр җәлеп итү һәм республика җитештерүчеләре продукциясен яңа базарларга чыгару өлкәсендә Россия Федерациясе регионнары һәм чит ил партнерлары белән хезмәттәшлекне үстерү;

халыкара икътисадый кооперация пространствосыннан актив файдалану;

электрон сәүдәне үстерү (шул исәптән Республика маркетинг үзәге мөмкинлекләреннән файдаланып);

эшкуарлыкка ярдәм күрсәтү инфраструктурасын, шул исәптән махсус икътисадый зоналарны, үсеше алдан билгеләнә торган территорияләрне, инновацион фәнни-технологик үзәкләрне, технопаркларны, индустриаль паркларны үстерү;

цифрлы икътисадны булдыру һәм үстерү;

технологик суверенитетны тәэмин итүгә ярдәм итә торган проектларны гамәлгә ашыру;

экспортка юнәлдерелгән тармакларда проектларны гамәлгә ашыру;

азык-төлек иминлеген тәэмин итүгә һәм авыл хуҗалыгы

җитештерүенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән инвестиция проектларын гамәлгә ашыру.

Шулай ук ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасы Инвестиция меморандумында билгеләнгән инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре буенча өстенлекле инвестиция проектлары исемлеге раслана.

Татарстан Республикасы икътисадының тулаем төбәк продукты структурасында иң зур урын биләгән төп тармакларына түбәндәгеләр керә:

1) сәнәгать, шул исәптән файдалы казылмалар чыгару һәм эшкәртү производстволары. 2023 ел йомгаклары буенча төяп җибәрелгән сәнәгать продукциясе күләме 4 742,3 млрд сум тәшкил итте;

2) төзелеш. 2023 ел йомгаклары буенча төзелеш эшләре күләме 708,1 млрд сум тәшкил итте;

3) авыл хуҗалыгы. 2023 ел йомгаклары буенча авыл хуҗалыгы продукциясе күләме 289,2 млрд сум тәшкил итте.

Татарстан Республикасының инвестиция проектларын гамәлгә ашырырга планлаштырыла торган икътисад тармаклары (яңа инновацион тармакларны кертеп) исемлеге Инвестиция декларациясенә 2 нче кушымтада күрсәтелде.

Татарстан Республикасында инвестицион үсеш өчен перспективалы юнәлешләр:

1) ашлыкны тирәнтен эшкәртү (бөртекле крахмал, модификацияләнгән крахмал, аксым, глютен, глюкозалы җиләк-җимеш сироплары җитештерү);

2) авыл хуҗалыгы җайланмасы (тракторлар, культиваторлар, сабаннар, чәчү комплекслары, туфракны тирән йомшарткычлар җитештерү);

3) төзелеш материаллары сәнәгате (цемент, керамик плитә, керамогранит җитештерү);

4) төзелеш (күпфатирлы торак төзелеше, индивидуаль торак төзелеше, мәгариф, сәламәтлек саклау, спорт, мәдәният һәм ял итү үзәкләре тармакларында социаль объектлар төзү);

5) телекоммуникация (челтәр), компьютер һәм сервер җиһазлары (җитештерү технологияләре, җитештерү өчен җиһазлар (җитештерү линиясе), ярымүткәргеч эшләнмәләр, SMD-компонентлар, продукция өчен корпуслар) җитештерү;

6) ярымүткәргеч эшләнмәләр, шул исәптән микропроцессорлар җитештерү (җитештерү технологияләре, җитештерү өчен җиһазлар (җитештерү линиясе), кремний пластиналар, фоторезистлар, фотошаблоннар, продукция өчен корпуслар, электрон модульләр җитештерү);

7) киберкуркынычсызлык;

8) синтетик тукымалар җитештерү (әзер синтетик тукымалар: полиэстер, акрил, эластан, нейлон җитештерү);

9) станок инструментлар сәнәгате (инструментлар, фрезер һәм токарь эшкәртү үзәкләре, станокларның аерым компонентларын, подшипниклар җитештерү).»;

д) 3.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.15. Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге «Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» 2010 елның 2 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә гамәлгә ашырыла, анда Татарстан Республикасы инновацион сәясәтенең максатлары, бурычлары һәм принциплары билгеләнгән. Татарстан Республикасында фәнне, технологияләрне һәм техниканы үстерүнең өстенлекле юнәлешләре исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 декабрендәге б-2957 нче боерыгы белән расланды.»;

е) 5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Татарстан Республикасы инвестиция командасы составы Инвестиция декларациясенә 3 нче кушымтада бирелде.»;

ж) 2028 елга кадәр Татарстан Республикасы Инвестиция декларациясенә кушымтада:

башисемендә «кушымта» сүзен «1 нче кушымта» сүзләренә алыштырырга;

51 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«51. 2024 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023–2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында» 2023 елның 18 декабрендәге 1637 нче карары.»;

з) түбәндәге эчтәлекле 2 нче кушымта өстәргә:

«2028 елга кадәр
Татарстан Республикасы
Инвестиция декларациясенә
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасының инвестиция проектларын гамәлгә ашыру планлаштырыла торган икътисад тармаклары, яңа инновация тармакларын кертеп, исемлеге**

| Т/с | Татарстан Республикасының инвестиция проектларын гамәлгә ашырырга планлаштырыла торган икътисад тармаклары, яңа инновация тармакларын кертеп, атамалары | Үсешнең төп өстенлекләре |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Файдалы казылмалар чыгару | Нефть чыгаруның ресурс базасын киңәйтү һәм югары үзле нефть һәм табигый битумнар ятмаларын эшкәртү; иярчен нефть газын чыгару һәм куллану |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | технологияләренең нәтиҗәлелеген арттыру, әлеге секторларда яңа куәтләр булдыру;<br>геологик разведка эшләре алып бару һәм скважиналарны тикшерү өчен яңа җиһазлар, сейсморазведканың яңа төрләрен үткәрү технологияләре өчен программа комплексларын булдыру һәм аларны гамәлгә кертү;<br>нефть чыгару, нефть һәм иярчен нефть газын транспортлау өчен яңа насос җиһазларын, энергия нәтиҗәле кулланыла торган җайланмалар эшләү һәм гамәлгә кертү;<br>нефть, газ һәм газ конденсаты чыгаруны интенсификацияләү процессларының, шул исәптән, ятмаларны су ярдәмендә варуның яңа технологияләрен, реагентларын, җиһазларын, математик алгоритмнарын эшләү һәм гамәлгә кертү;<br>нефть һәм газ чыгарганда мәгълүмат технологияләрен куллану өлкәләрен киңәйтү;<br>нефть һәм иярчен нефть газын транспортлауның ышанычлылыгын тәэмин итү |
| 2.1 | Кокс һәм нефть продуктлары җитештерү | Углеводород ресурсларын тирәнтен эшкәртү өлкәсендә конкурентлыкка сәләтле технологияләр кертү;<br>җитештерелә торган мотор ягулыгының һәм синтетик майларның сыйфатын яхшырту;<br>югары үзле нефть һәм табигый битумнарны эшкәртү технологияләрен эшләү |
| 2.2 | Химик матдәләр һәм химик продуктлар җитештерү | Түбәндәгеләрне булдыру:<br>полимер композиция материаллары җитештерү;<br>химия һәм нефть химиясе өлкәсендә яңа материаллар, шул исәптән инженерлык һәм конструкция пластмасслары, бер-берсен тоташтыра торган материаллар җитештерү һәм аларның технологияләре полимерлар һәм башка органик химия продуктлары җитештерү өчен нигез чималы кытлыгын киметү мөмкинлеге бирәчәк эре тоннажлы нефть химиясе һәм газ химиясе производстволары;<br>гамәлдәге тармак производстволарының үзкыйммәтен киметергә, катнаш тармакларның химия һәм нефть химиясе продукциясенә ихтыяҗын канәгатьләндерү мөмкинлеге бирәчәк химия һәм нефть химиясе продукциясенең импортын алыштыра торган производстволары;<br>тармакның пилот инновация проектларын эшкәртү инфраструктурасы;<br>химия процессларының моделен компьютер ярдәмендә ясау технологияләре;<br>биологик таркала торган полимер эшләнмәләр технологияләре һәм аларны җитештерү;<br>биомассадан (яңартыла торган чималдан) химия продукциясе технологияләре һәм аларны җитештерү.<br>Кластерлы үзара хезмәттәшлек (химия һәм нефть химиясе предприятиеләре, икътисадның башка тармакларындагы |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | җитештерүчеләр, фәнни оешмалар арасында).<br>Полимерларны, каучукларны дөньякүләм дәрәҗәдә җитештерүдә республика компанияләренең өлешен арттыру, глобаль химия һәм нефть химиясе производствосының яңа базарларына чыгу |
| 2.3 | Кәгазь һәм кәгазь эшләнмәләре, җиһазлар җитештерү, агач эшкәртү һәм җиһазлардан кала, агач эшләнмәләре җитештерү | Импортны алмаштыра торган продукциянең номенклатурасын һәм ассортиментын киңәйтү;<br>җиһазларны модернизацияләү;<br>агачны тирәнтен эшкәртү буенча җитештерү куәтләрен арттыру;<br>җиһазлар җитештерүләрен һәм материаллар һәм комплектлау әйберләре җитештерүне киңәйтү |
| 2.4 | Медицина максатларында кулланыла торган дарулар һәм материаллар җитештерү | Сәнәгать эшчәнлеге субъектлары, инжинирингның тармак үзәкләре, профильле фәнни һәм уку йортлары катнашында сәнәгать кластерлары булдыруны үз эченә алган кластерлы активлашу;<br>республиканың дарулар һәм медицина әйберләре җитештерүчеләренең, шулай ук җитештерүчеләр белән кооперациядә эшләүче дәүләт фән һәм мәгариф учреждениеләренең җитештерү куәтләрен технологик яктан яңадан җиһазлау һәм конкурентлыкка сәләтле продукция чыгару өчен фәнни-тикшерену потенциалын булдыру;<br><br>Татарстан Республикасының фармацевтика сәнәгатендә импорт аналогларын алмаштыручы стратегик әһәмиятле дауларны һәм тормыш өчен кирәкле һәм мөһим дару препаратларын чыгару;<br>инновация продукциясе базарына чыгу |
| 2.5 | Текстиль эшләнмәләр җитештерү | Милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру;<br>җиңел сәнәгать предприятиеләренең конкурентлыкка сәләтен арттыру һәм реструктуризацияләү;<br>продукция җитештерүнең технологик линияләрен модернизацияләү;<br>импортны алмаштыра торган продукциянең номенклатурасын һәм ассортиментын киңәйтү;<br>нефть һәм газ химиясе кластеры белән кушылу дәрәҗәсен арттыру |
| 3 | Агросәнәгать комплексы | Түбәндәге предприятиеләр төзү һәм (яки) модернизацияләү:<br>ашлыкны тирәнтен эшкәртү буенча;<br>майлы культураларны эшкәртү буенча;<br>сөтне тирәнтен эшкәртү буенча.<br>Сөт һәм ит терлекчелеге, нәселле терлекчелек:<br>сөт һәм ит бирә торган терлекчелекне үстерү,<br>генетиканы яхшырту хисабына сөт һәм ит җитештерү күләмнәрен арттыру;<br>терлек азыгы үзәкләрен, терлекләр һәм аларны ашату белән идарә итү программаларын кертү, яңа терлекчелек фермалары һәм комплекслары төзү |
| 4 | Мәгълүмат | Социаль өлкә тармакларында мәгълүмат-коммуникация |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | технологияләре, коммуникацияләр һәм мәгълүмати куркынычсызлык | технологияләрен кертү, мәгарифнең, медицина хезмәте күрсәтүнең, халыкны социаль яклауның сыйфатын яхшырту, мәгълүмат һәм телекоммуникация технологияләрен кулланып, мәдәни аң-белем бирү системасын үстерү;<br>Автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан (АМС) файдаланып, күпфункцияле үзәкләр (КФҮ) базасында дәүләт хезмәтләре, муниципаль һәм социаль әһәмияткә ия хезмәтләр күрсәтүләрдән электрон рәвештә файдалану, шулай ук «бер тәрәзә» режимында хезмәт күрсәтү мөмкинлеген тәэмин итү;<br>дәүләт идарәсенең һәм җирле үзидарәнең нәтиҗәлелеген, заманча мәгълүмат-коммуникация технологияләрен кулланып, граждан җәмгыяте һәм бизнесның дәүләт хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлеге арттыру;<br>Татарстан Республикасының бердәм геомәгълүмат киңлеген үстерү;<br>Татарстан Республикасы территориясендә заманча мәгълүмат һәм телекоммуникация инфраструктурасын булдыру, аның нигезендә сыйфатлы хезмәтләр күрсәтү һәм халык өчен мәгълүматтан һәм технологияләрдән файдалануны югары дәрәҗәдә тәэмин итү;<br><br>Татарстан Республикасының мәгълүмат куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм дәүләт хакимияте органнарының мәгълүмат ресурсларын саклау;<br>ведомствоара хезмәттәшлек мәсьәләләрен нәтиҗәле хәл итү, гамәлдә булган дәүләт мәгълүмат системаларын бердәм белешмәләр базасында туплау, дәүләт һәм муниципаль идарә һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү процессларын үзгәртеп кору мөмкинлеге бирәчәк бердәм комплекслы оештыру-техник экосистема формалаштыруны тәэмин итү;<br>цифрлы рәвештә күрсәтелә торган хезмәтләрнең (сервисларның) төрләрен, аларны гамәлгә ашыруда клиентларның ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән ысулларны куллануны арттыру хисабына гражданнарның гаризаларыннан башка гына дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә күчү;<br>хакимият органнары эшчәнлеген планлаштыруда, эшчәнлек йомгакларын мониторинглауда һәм бәяләүдә нәтиҗәлелекне тәэмин итү һәм арттыруда цифрлы технологияләрне куллану;<br>кадрларның цифрлы технологияләр өлкәсендә компетенцияләрен һәм белемнәрен арттыру максатларында даими рәвештә яңадан әзерлек программалары буенча укыту;<br>Татарстан Республикасы икътисадының гомуми өлешендә цифрлы бизнесның өлешен арттыру;<br>Ведомствоара хезмәттәшлек мәсьәләләренең нәтиҗәле |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | хәл ителүен, мәгълүматлар бердәмлеге, дәүләт һәм муниципаль идарә процесслары реинжинирингы базасында гамәлдәге дәүләт мәгълүмат системаларын интеграцияләүне һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне күздә тота торган бердәм комплекслы оештыру-техник экосистема булдыруны тәэмин итү;<br>цифрлы нигезгә күчүдә бердәй мөмкинлекләр булдыру;<br>икътисадта һәм социаль өлкәдә дәүләт идарәсенең цифрлы өлгереш дәрәҗәсен арттыру |
| 5 | Һөнәри, фәнни һәм техник эшчәнлек | Ачык һәм конкурентлыкка сәләтле фәнни-мәгариф һәм инновация инфраструктурасын һәм фәнни-технологик өлкәгә институциональ ярдәм күрсәтүнең һәм җайга салуның нәтиҗәле системасын булдыру;<br>интеллектуаль продуктлар базарын һәм инновацион эшчәнлек нәтиҗәләрен булдыру;<br>фәнни, фәнни-техник, инновация эшчәнлеген оештыруның заманча принципларына һәм Россия һәм дөньякүләм тәҗрибәләренә туры килә торган тикшеренүләр үткәрү һәм эшләнмәләр ясау өчен шартлар тудыру;<br>Татарстан Республикасының Smart market space бердәм цифрлы платформасын булдыруны үз эченә ала торган бердәм интеллектуаль фәнни-белем бирү киңлеген булдыру;<br>Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсешен кызыксындыру ысулы буларак яңа инновация продуктлары булдыру яки гамәлдәге продуктларны арттыру өчен инновация күнекмәләрен үстерүне тәэмин итә торган инновация ваучерларын кулланышка кертү;<br>гамәли тикшеренүләр һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре уздыруны тәэмин итә торган инжиниринг һәм пилот инфраструктурасын булдыру |
| 6 | Транспорт комплексы | Россиянең бердәм транспорт киңлеге составында Татарстан Республикасының балансланган нәтиҗәле транспорт инфраструктурасын булдыру;<br>Татарстан Республикасы икътисадын үстерү ихтыяҗлары дәрәҗәсендә транспорт-логистика хезмәтләреннән һәркем файдалана алу мөмкинлеген һәм аларның сыйфатын тәэмин итү, республиканың транзит потенциалын гамәлгә ашыру;<br>Татарстан Республикасы халкы өчен транспорт хезмәтләреннән һәркем файдалану мөмкинлеген һәм аларның сыйфатын тәэмин итү;<br>республика транспорт системасының әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын киметү |
| 7 | Туризм | Татарстан Республикасында заманча туристлык инфраструктурасы булдыру һәм үстерү |
| 8 | Электрон сәүдәне үстерү, шул исәптән Республика маркетинг үзәге мөмкинлекләрен | Татарстан Республикасында интернет аша сәүдә итү инфраструктурасын үстерү (логистика);<br>Татарстан Республикасы КУЭ субъектларына, контент эшләп, электрон сәүдә мәйданчыкларында товарларны |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | файдалану | урнаштыруда ярдәм күрсәтү;<br>Татарстан Республикасы КУЭ субъектларына һәм үзмәшгуль гражданнарга электрон сәүдә мәйданчыкларына чыгу буенча чаралар оештыру һәм үткәрү;<br>Татарстан Республикасы КУЭ субъектларына халыкара электрон сәүдә мәйданчыкларында товарлар урнаштыруда ярдәм күрсәтү һәм аларга алга таба булышлык итү |
